**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**29 сентябрь, 2023 ел** **№ 325**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы беренче өлешенең 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 33 статьялары, Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча 2023 елның 23 августындагы гавами тыңлаулар беркетмәсе, Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2023 елның 15 сентябрендәге бәяләмәсе, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисаметдинов

Кушымта

Татарстан Республикасы
Биектау муниципальн районы Советының
2023 елның 29 сентябрендәге 325
номерлы карары белән расланды

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ

# ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ АЛЫП БАРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

## I КИСӘК.

ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕН КУЛЛАНУ ТӘРТИБЕ,
ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ

2023 ел

ЭЧТӘЛЕК

 ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕНЕҢ СОСТАВЫ ………………4
КЕРЕШ…………………………………………………………………………………........**Ошибка! Закладка не определена.**
 I КИСӘК. ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕН КУЛЛАНУ ТӘРТИБЕ, ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ ..........................................................................................................................................**Ошибка! Закладка не определена.**
I БҮЛЕК. Гомуми нигезләмәләр ………………………………………………………6
1 статья. Әлеге кисәктә кулланыла торган төп төшенчәләр ............………………………………**Ошибка! Закладка не определена.**
2 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең хокукый статусы һәм составы ………..**Ошибка! Закладка не определена.**
3 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш турында мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы ……………..........................................................................................**Ошибка! Закладка не определена.**
4 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең үз көченә керүе ………………………..9
5 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен бозу өчен җаваплылык …..……………...**Ошибка! Закладка не определена.**
II БҮЛЕК. Җирле үзидарә органнары тарафыннан җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу турында нигезләмәләр …………………………………………………………………………………**Ошибка! Закладка не определена.**
6 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре ........**Ошибка! Закладка не определена.**
7 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия ……..**Ошибка! Закладка не определена.**
8 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең элек барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата гамәле ..............................................................................................10
9 статья. Территориаль зоналар ………………………………………………………..11
10 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары …………………………………………...12
11 статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлегенең башка мәсьәләләренә карата җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең гамәле ………………………………………………………..13
III БҮЛЕК. Физик һәм юридик затлар тарафыннан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртү турында нигезләмәләр ………**Ошибка! Закладка не определена.**
12 статья. Төп нигезләмәләр ………………………………………………………………..**Ошибка! Закладка не определена.**
13 статья. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү тәртибе ………………………………....................................**Ошибка! Закладка не определена.**
14 статья. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү тәртибе ……..........................................**Ошибка! Закладка не определена.**
 IV БҮЛЕК. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында нигезләмәләр ……....**Ошибка! Закладка не определена.**
15 статья. Төп нигезләмәләр ………………………………………………………………..**Ошибка! Закладка не**

**определена.**
V БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча җәмәгать фикер алышулары яки гавами тыңлаулар уздыру турында нигезләмәләр
…………………………………………..**Ошибка! Закладка не определена.**
16 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча җәмәгать фикер алышулары яки гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыруның гомуми нигезләмәләре
……………………………...**Ошибка! Закладка не определена.**
17 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектлары буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар уздыру үзенчәлекләре …………………………………………………………………18
18 статья. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар
…………………………………………………………….....................................**Ошибка! Закладка не определена.**
19 статья. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар
………………………………………….........................**Ошибка! Закладка не определена.**
VI БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү нигезләмәләре **Ошибка! Закладка не определена.**
20 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе ...........**Ошибка! Закладка не определена.**
VII БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелешнең башка мәсьәләләрен җайга салу нигезләмәләре **Ошибка! Закладка не определена.**
21 статья. Территориаль зоналар чикләре турында мәгълүматны күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрына кертү
……………………………………........................................................**Ошибка! Закладка не определена.**

# ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕНЕҢ СОСТАВЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге составта эшләнгән:

**I кисәк.** Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану тәртибе, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе

**II кисәк.** Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары

График материаллар:

| **№ т/б** | **Исеме** | **Масштаб** |
|---|---|---|
| 1 | Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы.<br>Территориаль зоналар | 1:10 000 |
| 2 | Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы.<br>Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре | 1:10 000 |

**III кисәк.** Шәһәр төзелеше регламентлары

**Кушымта**
Территориаль зоналар чикләре турында белешмәләр

## КЕРЕШ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) – территориаль зоналар, шәһәр төзелеше регламентлары, аны куллану тәртибе һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибе билгеләнә торган җирле үзидарә органының норматив хокукый акты белән раслана торган шәһәр төзелешен зоналаштыру документы.

Кагыйдәләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының түбәндәге норматив хокукый актлары таләпләрен исәпкә алып әзерләнде:

– Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 29.12.2004 ел №190-ФЗ;

– Россия Федерациясе Җир кодексы 25.10.2001 ел № 136-ФЗ;

– Россия Федерациясе Урман кодексы 04.12.2006 ел № 200-ФЗ;

– Россия Федерациясе Су кодексы 03.06.2006 ел № 74-ФЗ;

– «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

– «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

Кагыйдәләрне әзерләгәндә шулай ук Биектау муниципаль районының һәм «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актлары нигезләмәләре, «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый һәм шәһәр төзелеше үсешенең төп юнәлешләрен билгели торган башка документлар исәпкә алына.

## I КИСӘК. ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ АЛЫП БАРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕН КУЛЛАНУ ТӘРТИБЕ, ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ АЛЫП БАРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ

### I БҮЛЕК. Гомуми нигезләмәләр

#### 1 статья. Әлеге кисәктә кулланыла торган төп төшенчәләр

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан рөхсәт ителгән файдалану төре** – җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның мөмкин булган ысулы. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре рөхсәт ителгән файдалануның төп, шартлы рөхсәт ителгән, ярдәмче төрләрен үз эченә ала һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы раслаган классификатор нигезендә билгеләнә.

**Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре** – җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре, алар белән бергә гамәлгә ашырыла торган рөхсәт ителгән файдалануның төп һәм шартлы рөхсәт ителгән төрләренә карата өстәмә буларак кына рөхсәт ителә.

**Шәһәр төзелешен зоналаштыру** – территориаль зоналарны билгеләү һәм шәһәр төзелеше регламентларын билгеләү максатларында муниципаль берәмлекләр территорияләрен зоналаштыру.

**Шәһәр төзелеше регламенты** –тиешле территориаль зона чикләре чикләрендә билгеләнә торган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре, шулай ук җир кишәрлекләре өстендә һәм җир өслегендә булган нәрсәләр, аларны төзү һәм капиталь төзелеш объектларын эксплуатацияләү процессында файдаланыла торган барлык төрләре, җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләү, шулай ук чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру каралган территорияләргә карата куллану, халык өчен тиешле территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм күрсәтелгән объектларның территориаль файдалана алуының максималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре.

**Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе** – Кагыйдәләр әзерләүне оештыру, аларга үзгәрешләр кертү, гавами тыңлаулар уздыру һәм Кагыйдәләрне әзерләү Комиссиясе турындагы нигезләмә нигезендә башка мәсьәләләрне хәл итү максатында законнар, муниципаль хокукый актлар нигезендә төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган.

**Кызыл линияләр** – гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен күрсәткән һәм территорияне планлаштыру документларында билгеләнергә, үзгәртелергә яисә бетерелергә тиешле линияләр.

**Линияле объектлар** – электр тапшыру линияләре, элемтә линияләре (шул исәптән линия-кабель корылмалары), торба үткәргечләр, автомобиль юллары, тимер юл линияләре һәм башка шундый корылмалар.

**Төзелеш алып баруның максималь проценты** - төзелеш алып барылырга мөмкин булган җир кишәрлегенең суммар мәйданы, җир кишәрлегенең бөтен мәйданына (%) мөнәсәбәте.

**Җир кишәрлеге чигеннән бинаның, төзелешнең, корылмаларның минималь чигенеше** – җир кишәрлеге чиге белән бина, төзелеш яки корылма арасындагы ераклык.

**Капиталь төзелеш объектлары -** биналар, корылмалар, төзелешләре тәмамланмаган объектлар, җир кишәрлегенең капиталь булмаган төзелмәләреннән, корылмаларыннан һәм аерылгысыз яхшыртуларыннан тыш (ныгытма, өслек һәм башкалар).

**Капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар** – җир белән ныклы бәйләнеше булмаган һәм конструктив характеристикалары аларны күчереп йөртү һәм (яисә) демонтаж үткәрү һәм аннан соңгы җыелуны төзелешләрнең, корылмаларның (шул исәптән киоскларның, түбәләрнең һәм башка шундый корылмаларның) төп характеристикалары үзгәртелмичә һәм билгеләнүгә тулысынча зыян китермичә һәм аннан соңгы җыемнарны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә торган төзелмәләр, корылмалар.

**Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән төп төрләре** – әлеге эшчәнлек төрләрен һәм шәһәр төзелеше регламентлары составындагы объектларны тиешле территориаль зоналарга карата күчерү нәтиҗәсендә мөмкин булган җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре,

**Индивидуаль торак төзелеше объекты** – гражданнар тарафыннан мондый бинада яшәү белән бәйле көнкүреш һәм башка ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен билгеләнгән бүлмәләрдән һәм ярдәмче куллану биналарыннан торган һәм күчемсез мөлкәтнең мөстәкыйль объектларына бүлү өчен билгеләнмәгән җир өсте катлары саны өчтән, биеклеге егерме метрдан артмаган аерым бина.

**Җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары хокук ияләре** – җир милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен, капиталь төзелеш объектларын арендалаучылар, аларның вәкаләтле затлары.

**Җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары** –җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь күләмнәре, шул исәптән аларның мәйданы; биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны мөмкин булган урнаштыру урыннарын билгеләү максатларында җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенүләр; биналарның, төзелешләрнең, корылмаларның иң чик саны яисә иң чик биеклеге; тиешле территориаль зоналарга карата шәһәр төзелеше регламентлары нигезендә билгеләнә торган җир кишәрлеге чикләрендә төзүнең максималь проценты.

**Гавами сервитут** – Россия Федерациясе законы яисә башка норматив хокукый акты, Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты, җирле үзидарә органының норматив хокукый акты белән билгеләнгән җир кишәрлегеннән үзенә карата билгеләнә торган җир кишәрлекләрен тартып алмыйча гына чикләнгән файдалану хокукы.

**Гавами тыңлаулар, җәмәгать фикер алышулары** –законнарда билгеләнгән очракларда җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу өчен муниципаль берәмлек (җәмәгатьчелек) халкының хокукларын гамәлгә ашыру формасы.

**Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт** – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40 статьясы таләпләре нигезендә бирелә торган, җир кишәрлеге иясенә капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру, шулай ук аларны капиталь ремонтлауга тиешле территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга хокук бирә торган документ.

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт** – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы таләпләре нигезендә җир кишәрлекләренә хокук ияләренә җир кишәрлегеннән, әлеге Кагыйдәләр белән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектыннан файдалану төрен сайлау хокукын бирә торган документ.

**Территориаль зоналар** – җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә алар өчен чикләр билгеләнгән һәм шәһәр төзелеше регламентлары куелган зоналар.

**Гомуми файдалану территорияләре** – чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксыз файдалана торган территорияләр (шул исәптән мәйданнар, урамнар, узу юллары, яр буйлары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосалары, скверлар, бульварлар).

**Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләре** – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39

статьясында билгеләнгән тәртиптә рөхсәт алу шарты белән, әлеге эшчәнлек төрләрен һәм шәһәр төзелеше регламентлары составындагы объектларны тиешле территориаль зоналарга карата күчерү нәтиҗәсендә мөмкин булган җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре.

**2 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең хокукый статусы һәм составы**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре җирле үзидарә органының норматив хокукый акты статусына ия.

2. Әлеге Кагыйдәләр түбәндәгеләр белән беррәттән кулланыла:

техник регламентлар (алар үз көченә кергәнче билгеләнгән тәртиптә - 2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы «Техник җайга салу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына каршы килми торган өлешендә норматив техник документлар);

Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары;

шәһәр төзелешен проектлау нормативлары;

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең һәм Биектау муниципаль районының җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлары.

3.Әлеге Кагыйдәләр үз эченә ала:

Кереш;

I Кисәк. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану тәртибе, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе;

II Кисәк. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары;

III Кисәк. Шәһәр төзелеше регламентлары;

Кушымталар.

4. Әлеге Кагыйдәләр «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелешен көйләүче яисә контрольдә тотучы вазыйфаи затлар тарафыннан дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар, вазыйфаи затлар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

**3 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш турында мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы**

1. Әлеге Кагыйдәләр, аларның составына керүче барлык картографик һәм башка документларны да кертеп, барлык физик һәм юридик, шулай ук вазыйфаи затлар, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарына һәркем файдалана алырлык була.

2. «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары әлеге Кагыйдәләр белән танышу мөмкинлеген түбәндәге юллар белән тәэмин итәләр:

әлеге Кагыйдәләрне җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларын, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару (халыкка җиткерү), һәм «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең яки муниципаль районның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру;

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелешне җайга салу мәсьәләләрендә катнашучы органнарда һәм оешмаларда әлеге Кагыйдәләр белән тулы комплектта танышу өчен мөмкинлек тудыру;

3. Муниципаль районның җирле үзидарә органнары әлеге Кагыйдәләр белән танышу мөмкинлеген түбәндәге юллар белән тәэмин итәләр:

Кагыйдәләрне территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру;

физик һәм юридик затларга әлеге Кагыйдәләрдән өземтәләр, шулай ук картографик материалларның кирәкле күчермәләрен һәм җирдән файдалану һәм төзелеш шартларын аерым җир кишәрлекләренә һәм планировка структурасы элементларына карата характерлаучы аларның фрагментларын бирү. Югарыда күрсәтелгән затларга әлеге материаллар язма сорату буенча биреләләр.

**4статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең үз көченә керүе**

1. Әлеге Кагыйдәләр җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән үз көченә керә.

2. Кагыйдәләр зуррак юридик көчкә ия булган хокукый актларга каршы килми торган өлештә эшли.

**5 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен бозу өчен җаваплылык**

1. Әлеге Кагыйдәләрне бозган өчен физик һәм юридик затлар, шулай ук вазыйфаи затлар Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы булалар.

## II БҮЛЕК. Җирле үзидарә органнары тарафыннан җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу турында нигезләмәләр

**6 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә билгеләнә.

2. «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә башкарма органының (алга таба - җирлек Башкарма комитеты) җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә вәкаләтләренә керә:

территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш);

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләүне тәэмин итү;

үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү турында яки үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яисә аны Кагыйдәләрдә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларына туры китерү турында, яисә, гражданнар законнарында каралган очракларда, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләренә туры китерү турында карар кабул итү;

3. Биектау муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы (алга таба - муниципаль район Советы) җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендәге вәкаләтләренә керә:

авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен, шул исәптән Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләрне (өстәмәләрне) раслау;

муниципаль районның шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау;

җирлек шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау;

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау.

4. Биектау муниципаль районы җирле үзидарәсенең башкарма органы (алга таба - муниципаль районның Башкарма комитеты) җирдән файдалану һәм төзелеш өлкәсендә вәкаләтләренә керә:

территорияне планлаштыру документларын раслау (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очракларда);

төзелешкә рөхсәтләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш);

муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда хәбәрнамәләр (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш) җибәрү;

җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру;

муниципаль район территориясендә гамәлгә ашырыла торган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып бару;

муниципаль ихтыяҗлар өчен җирлек чикләрендә җир кишәрлекләрен резервлау һәм алу.

Әлеге Кагыйдәләр нигезендә муниципаль район Башкарма комитеты вәкаләтләренә шулай ук карыйлар:

җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтләр бирү;

капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү.

**7 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе**

1. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия) «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә Кагыйдәләр проектын әзерләүне, Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертүне оештыру, Кагыйдәләрне гамәлгә ашыру максатында төзелә.

2. Комиссия үз эшчәнлеген әлеге Кагыйдәләр, Комиссия турындагы нигезләмә, җирле үзидарә органнарының, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Комиссия вәкаләтләренә керә:

әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертүне оештыру;

Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү мәсьәләләре буенча гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;

Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проекты, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча җәмәгать фикер алышулары һәм гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү;

җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләр әзерләү, тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрү;

Комиссия турында нигезләмә белән аңа йөкләнгән башка вәкаләтләр.

4. Комиссия карарлары беркетмәгә имза салынган мизгелдән үз көченә керә һәм тиешле гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан тәкъдимнәр була.

5. Комиссия эше турында мәгълүмат барлык кызыксынучы затлар өчен ачык була.

**8 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең элек барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата гамәле**

1. Әлеге Кагыйдәләрне раслаганчы җирле үзидарә органнарының җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча кабул ителгән норматив хокукый актлары әлеге Кагыйдәләргә каршы килми торган өлештә кулланыла.

2. Җир кишәрлеге яисә капиталь төзелеш объекты әлеге Кагыйдәләргә туры килми, әгәр:

аларның рөхсәт ителгән файдалану төрләре тиешле территориаль зона өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән куллану төрләре исемлегенә кермәсә;

аларның күләмнәре һәм параметрлары тиешле территориаль зонаның шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән иң чик күрсәткечләргә туры килмәсә.

3. Шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган җир кишәрлекләре яисә капиталь төзелеш объектлары, рөхсәт ителгән файдалану төрләре, иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) зурлыклары һәм иң чик параметрлары аларны шәһәр төзелеше регламентына туры китерү срогын билгеләмичә генә файдаланылырга мөмкин, моңа мондый җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану кеше тормышы яисә сәламәтлеге өчен куркыныч, әйләнә-тирә мохит, мәдәни мирас объектлары өчен куркыныч булган очраклар керми.

4. Җир кишәрлекләреннән яисә капиталь төзелеш объектларыннан, рөхсәт ителгән файдалану төрләреннән файдалану, иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) зурлыклары һәм иң чик параметрлары шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган очракта, кеше гомере яисә сәламәтлеге, әйләнә-тирә мохит, мәдәни мирас объектлары өчен куркыныч һәм куркыныч янаган очракта, федераль законнар нигезендә мондый җир участокларын һәм объектларны куллануны тыю салынырга мөмкин.

5. Рөхсәт ителгән файдалану төрләре яисә чикле параметрлары шәһәр төзелеше регламентына туры килми торган капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, мондый объектларны тиешле территория зонасының шәһәр төзелеше регламентына туры китерү юлы белән генә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

**9 статья. Территориаль зоналар**

1. Территориаль зоналар түбәндәгеләрне исәпкә алып билгеләнә:

җир кишәрлекләреннән гамәлдәге һәм планлаштырыла торган файдалануның төрле төрләренең бер территориаль зонасы чикләрендә яраштыру мөмкинлекләрен;

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы белән билгеләнгән функциональ зоналарының һәм аларның планлаштырыла торган үсеш параметрларының;

барлыкка килгән территорияне планлаштыру һәм гамәлдәге җирдән файдалануны;

төрле категориядәге җирләрнең чикләренең планлаштырылган үзгәрешләрен;

аралаш җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларына зыян китерү мөмкинлеген булдырмауны;

мәдәни мирас объектларының сак зоналары проектларын.

2. Территориаль зоналарның чикләре түбәндәгеләр буйлап билгеләнә:

автомобиль юлларының, урамнарның, узу юллары күчәрләре;

кызыл сызыклар;

җир кишәрлекләре чикләре;

табигать объектларының табигый чикләре;

торак пунктлары чикләре;

муниципаль берәмлекләр чикләре;

башка чикләр.

3. Территориаль зоналар чикләре һәр җир кишәрлегенең бары тик бер территориаль зонага гына туры килү таләбенә җавап бирергә тиеш, чикләре җир законнары нигезендә территориаль зоналар чикләрен кисеп үтә ала торган җир кишәрлегеннән тыш.

4. Әлеге Кагыйдәләр белән һәр территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә.

**10 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары**

1. Шәһәр төзелеше регламентында шулай ук җир кишәрлекләре өслегендә булган һәм аларны төзү процессында һәм капиталь төзелеш объектларын эксплуатацияләү процессында кулланыла торган бөтен нәрсә кебек үк җир кишәрлекләренең хокукый режимы билгеләнә.

2. Шәһәр төзелеше регламентлары түбәндәгеләрне исәпкә алып билгеләнә:

территориаль зона чикләрендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан фактта файдалануны;

җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан гамәлдәге һәм планлаштырылган файдалануның төрле төрләренең бер территориаль зонасы чикләрендә яраштыру мөмкинлекләрен;

муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документларында билгеләнгән функциональ зоналарының һәм аларның планлаштырыла торган үсеш характеристикаларын;

территориаль зоналар төрләрен;

мәдәни мирас объектларын, шнулай ук аеруча саклanучы табигать территорияләрен, башка табигать объектларын саклау таләпләрен.

3. Шәһәр төзелеше регламентының гамәли көче тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан барлык җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына тигез дәрәҗәдә кагыла.

4. Шәһәр төзелеше регламенты түбәндәге җир кишәрлекләренә кагылмый:

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән ядкарьләр һәм ансамбльләр территорияләре чикләрендә, шулай ук мәдәни мирас объектлары ачыкланган ядкарьләр яисә ансамбльләр территорияләре чикләрендә һәм мәдәни мирас объектларын саклау турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кабул ителә торган реставрация, консервацияләү, торгызу, ремонтлау һәм җайлашу режимы турында карар кабул ителгән территорияләр чикләрендә;

гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрендә;

линия объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән һәм (яисә) линия объектлары куелган;

файдалы казылмалар чыгару өчен бирелгән.

5. Тарихи җирлекләр территорияләренә, истәлекле урыннарга, дәвалау-савыктыру урыннары җирләренә һәм курортларга, территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарга карата шәһәр төзелеше регламентлары Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

6. Шәһәр төзелеше регламентлары түбәндәгеләр өчен билгеләнми:

урман фонды җирләре;

өслек сулары белән капланган җирләр;

запас җирләр;

махсус саклanучы табигать территорияләре җирләре (дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар җирләреннән тыш);

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составындагы авыл хуҗалыгы җирләре;

махсус икътисадый зоналар һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре.

6.1. Урман фонды җирләреннән торак пунктлар чикләренә кертелгән җир кишәрлекләренә карата шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнгәнче (2016 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнарга яисә юридик затларга бирелгән яки аларда хокуклары 2016 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан һәм, рөхсәт ителгән файдаланылуы йә билгеләнеше аларны торак пункт чикләренә керткәнче урманнардан файдалану белән бәйле булмаган урман кишәрлекләреннән тыш), мондый җир кишәрлекләре урман законнары нигезендә шәһәр урманнарыннан файдаланганда билгеләнгән чикләүләрне исәпкә алып кулланыла.

7. Шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый торган яисә шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җир кишәрлекләрен куллану федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары тарафыннан федераль законнар нигезендә билгеләнә. Урман фонды җирләре составындагы җирләр яки җир кишәрлекләрен, махсус саклanучы табигать территорияләре

чикләрендә урнашкан җирләрдән яисә җир кишәрлекләреннән файдалану (махсус саклanучы табигать территорияләре составына кертелгән торак пунктлар территорияләреннән тыш) тиешенчә урман хуҗалыгы регламенты, урман законнары нигезендә махсус саклanучы табигать территориясе турындагы нигезләмә, махсус саклanучы табигать территорияләре турындагы законнар нигезендә билгеләнә.

8. Тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата шәһәр төзелеше регламентында күрсәтелә:

җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре;

җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрлары;

җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган чикләүләр;

территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм, шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә торган территориаль зона чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру каралган очракта, күрсәтелгән объектларның халык өчен территориаль файдалана алу мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре.

**11статья. Шәһәр төзелеше эшчәнлегенең башка мәсьәләләренә карата Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең гамәле**

1. Әлеге бүлектә күрсәтелгән очраклардан тыш, территориаль зоналар һәм шәһәр төзелеше регламентлары чикләре турында белешмәләр кулланыла:

территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләгәндә (әлеге схема нигезендә төзелергә тиешле җир кишәрлекләренең һәркайсына карата әлеге схеманы раслау турындагы карарда шул исәптән җир кишәрлеге төзелә торган территория зонасы күрсәтелә, яисә шәһәр төзелеше регламентының төзелә торган җир кишәрлегенә кагылмаса яисә төзелә торган җир кишәрлеге өчен төзелә торган җир кишәрлегеннән файдалану төре билгеләнмәсә);

территорияне планлаштыру документларын әзерләгәндә (территорияне планлаштыру документларын әзерләү Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре билгеләгән территориаль зоналарга карата гамәлгә ашырылырга мөмкин);

җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләгәндә (җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы составында шул исәптән, җир кишәрлегенә шәһәр төзелеше регламенты гамәлдә булган очракта, шәһәр төзелеше регламенты турында мәгълүмат күрсәтелә).

2. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаган очракта, федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге объектларын, шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый торган яисә шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнмәгән җир кишәрлекләрендә һәм федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш, төзелешкә рөхсәтләр бирүгә юл куелмый.

3. Шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый торган җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җирләргә карата Кагыйдәләр җир төзелеше эшләрен уздырганда җир кишәрлекләренә характеристика билгеләү максатыннан рөхсәт ителгән файдалануның рөхсәт ителгән төрләре билгеләнә.

4. Җирле үзидарә органнары Кагыйдәләрне раслау турында яки Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында карар кабул иткән очракта, әгәр мондый үзгәрешләр белән шәһәр төзелеше регламентын билгеләү яисә үзгәртү, территориаль зоналарның чикләрен билгеләү яисә үзгәртү каралган булса, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына белешмәләр кертү өчен документларны (аларда булган белешмәләрне) теркәү органына җибәрергә тиеш.

## III БҮЛЕК. Физик һәм юридик затларның җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен үзгәртүе турында нигезләмәләр

### 12 статья. Төп нигезләмәләр

1. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы җир кишәрлеге яисә капиталь төзелеш объекты турындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Тиешле территориаль зонага билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалануның төп һәм ярдәмче төрләре кулланылган шартта, рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләре тарафыннан мөстәкыйль рәвештә түбәндәге ысуллар белән гамәлгә ашырыла:

хокук иясе, рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында гариза, хокукны билгели торган документлар, шулай ук тиешле җир кишәрлеген аерым территориаль зонага (Кагыйдәләрдән өземтәгә) кертү турында муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән белешмә белән, әгәр тиешле территориаль зона турында белешмәләр күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булмаса, кадастр исәбе органына мөрәҗәгать итә;

хокук иясе җирле үзидарә органнарына мәгълүмат үзара хезмәттәшлеге тәртибендә җир кишәрлеге яисә капиталь төзелеш объекты характеристикаларын үзгәртү турында белешмәләр җибәрү өчен рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итә.

3. Тиешле территория зонасы өчен шартлыча рөхсәт ителгән башка төргә кагылышлы рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 13 статьясы нигезләмәләре нигезендә җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

4. Шәһәр төзелеше регламентлары гамәлдә булмаган яисә шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җирләрдә урнашкан җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен үзгәртү турындагы карарлар федераль законнар нигезендә мондый файдалануның башка төренә кабул ителә.

5. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның тиешле территориаль зона өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төрләре исемлегендә булмаган барлык башка төрләре әлеге территориаль зона өчен рөхсәт ителмәгән булып тора һәм әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр керткәндә генә рөхсәт ителергә мөмкин.

6. Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән көннән алып аңа карата аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территорияне планлаштыру документларын раслау көненә кадәр, мондый территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән һәм (яисә) капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү рөхсәт ителми.

### 13 статья. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү тәртибе

1. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирелүдә кызыксынучы физик яисә юридик зат (алга таба - файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт) Комиссиягә файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында гариза җибәрә.

Файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында гариза электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин

2. Файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм әлеге бүлекнең 18 статьясы нигезләмәләрендә билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган җәмәгать фикер алышуларында яки гавами тыңлауларда каралырга тиеш.

3. Файдаланунының шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә Комиссия, кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп, файдаланунының шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт яисә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимнәр әзерли һәм аларны «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрә.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәр нигезендә «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты җитәкчесе мондый тәкъдимнәр кергән көннән алып өч көн эчендә мондый рөхсәтне файдаланунының шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт яисә мондый рөхсәтне бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Күрсәтелгән карар муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга һәм «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең яисә муниципаль районның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

5. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән дәүләт хакимияте башкарма органыннан, вазыйфаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яисә җирле үзидарә органыннан үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау турында җирле үзидарә органына хәбәр кергән көннән башлап, мондый төзелеш урнашкан җир кишәрлегенә карата яисә мондый төзелешкә карата аны җимергәнче яисә билгеләнгән таләпләргә туры китергәнче, файдаланунының рөхсәт бирү рөхсәт ителми, әгәр җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән һәм әлеге хәбәрнамә кергән дәүләт хакимиятенең башкарма органына, вазыйфаи затка, дәүләт учреждениесенә яисә җирле үзидарә органына үз белдеге белән төзелгән билгеләрнең булмавы яисә үзбелдекле төзелешне җимерү турындагы дәгъваларны канәгатьләндерүдән баш тарту яисә билгеләнгән таләпләргә туры китерү турындагы суд карарының законлы көченә керүе хакында хәбәр юлланган очраклардан тыш.

6. Физик яисә юридик зат файдаланунының шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү яисә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карарга суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

**14 статья. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү тәртибе**

1. Күләмнәре шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән җир кишәрлекләренең минималь күләмнәреннән кимрәк яисә төзелеш алып бару өчен конфигурацияләре, инженерлык-геологик яисә башка характеристикалары уңайсыз булган булган җир кишәрлекләренең хокук ияләре капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.1. Җир кишәрлекләренең хокук ияләре, әгәр мондый тайпылыш конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылыш бер яисә берничә чик параметрны бер мәртәбә ун проценттан артмаган күләмдә үзгәртү максатларында кирәк булганда, рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылу өчен рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылу, техник регламентлар, норматив техник документлар таләпләрен үтәгәндә, аерым җир кишәрлеге өчен рөхсәт ителә.

Катларның иң чик саны, биналарның, корылмаларның чик биеклеге һәм федераль яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләрендә капиталь төзелеш объектларының архитектур чишелешләренә таләпләр өлешендә рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан тайпылу рөхсәт ителми.

3. Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт алу белән кызыксынучы зат Комиссиягә мондый рөхсәт бирү турында гариза җибәрә.

Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы гариза электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

4. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында карар проекты мондый рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән унбиш көн дәвамында әзерләнә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм әлеге бүлекнең 19 статьясы нигезләмәләрендә билгеләнгән тәртиптә җәмәгать фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда каралырга тиеш, әлеге статьяның 1.1. өлешендә каралган очрактан тыш.

5. Җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча Комиссия, мондый фикер алышулар яисә тыңлаулар узган көннән унбиш көн эчендә, кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп, мондый рөхсәт бирү турында яисә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимнәр әзерли һәм аларны муниципаль районның Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрә.

6. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән рекомендацияләр нигезендә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе мондый тәкъдимнәр кергән көннән җиде көн эчендә капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү яисә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

7. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән дәүләт хакимияте башкарма органыннан, вазыйфаи заттан, дәүләт учреждениесеннән яисә җирле үзидарә органыннан үз белдеге белән төзелгән корылманы ачыклау турында җирле үзидарә органына хәбәр кергән көннән башлап, мондый төзелеш урнашкан җир кишәрлегенә карата яисә мондый төзелешкә карата аны җимергәнче яисә билгеләнгән таләпләргә туры китергәнче, файдалануның рөхсәт бирү рөхсәт ителми, әгәр җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән һәм әлеге хәбәрнамә кергән дәүләт хакимиятенең башкарма органына, вазыйфаи затка, дәүләт учреждениесенә яисә җирле үзидарә органына үз белдеге белән төзелгән билгеләрнең булмавы яисә үзбелдекле төзелешне җимерү турындагы дәгъваларны канәгатьләндерүдән баш тарту яисә билгеләнгән таләпләргә туры китерү турындагы суд карарының законлы көченә керүе хакында хәбәр юлланган очраклардан тыш.

8. Физик яисә юридик зат рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан тайпылуга рөхсәт яисә мондый рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карарга суд тәртибендә ризасызлык белдерергә хокуклы.

9. Әгәр мондый тайпылыш аэродром янындагы территориядә билгеләнгән күчемсез милек объектларыннан файдалануны чикләүгә туры килмәсә, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирүгә юл куелмый.

## IV БҮЛЕК. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында нигезләмәләр

### 15 статья. Төп нигезләмәләр

1. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында гамәлгә ашырыла.

2. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү территориаль зоналарның һәм (яисә) муниципаль районнарны территориаль планлаштыру схемаларында билгеләнгән җирләрдән файдалану һәм (яисә) территорияләрне территориаль планлаштыру схемаларында билгеләнгән

планлаштыру структурасының бер яисә берничә чиктәш элементларына, җирлекләрнең, шәһәр округларының генераль планнарына карата функциональ зоналарга, аның комплекслы һәм тотрыклы үсеше буенча эшчәнлек гамәлгә ашыру каралган территориягә карата гамәлгә ашырыла.

3. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территориаль планлаштыру документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре нигезендә (линия объектларын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру документларын әзерләүдән тыш); коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программалары, транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программалары, социаль инфраструктураны комплекслы үстерү программалары, шәһәр төзелешен проектлау нормативлары, техник регламентлар, кагыйдәләр җыентыклары таләпләре нигезендә; Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларының инженерлык тикшеренүләре материалларын һәм нәтиҗәләрен, ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен, территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4. Территорияне планлаштыру документлары төрләренә түбәндәгеләр керә:

территорияне планлаштыру проекты;

территорияне межалау проекты.

5. Территорияне планлаштыру проектын әзерләү түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла:

планировка структурасы элементларын аерып чыгару;

гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен билгеләү (кызыл линияләр билгеләү юлы белән);

капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү;

территорияне планлаштырып үстерүнең характеристикаларын һәм чиратын билгеләү.

6. Территорияне межалау проектын әзерләү түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла:

төзелә торган һәм үзгәртелә торган җир кишәрлекләренең чикләре урынын билгеләү;

чикләрендә яңа капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырылмаган төзелеш территорияләре өчен кызыл линияләр билгеләү, үзгәртү, туктату, шулай ук территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлеге барлыкка килүгә һәм (яисә) үзгәрүгә бәйле рәвештә кызыл линияләр билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару өчен, территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү буенча эшчәнлек алып бару каралмаган территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлеген билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару өчен, мондый билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару гомуми файдаланудагы территориянең чикләрен үзгәртүгә генә китерә торган шартта.

Территорияне межалау проектын әзерләгәндә төзелә торган һәм (яисә) үзгәртелә торган җир кишәрлекләренең чикләре урынын билгеләү эшчәнлекнең конкрет төрләре өчен шәһәр төзелеше регламентлары һәм җир кишәрлекләрен бүлеп бирү нормалары, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән төзелә торган һәм (яисә) үзгәртелә торган җир кишәрлекләренә башка таләпләр, техник регламентлар, кагыйдәләр җыентыклары нигезендә гамәлгә ашырыла.

7. Территорияне планлаштыруның расланган проектлары һәм межалау проектлары нигезендә җирле үзидарә органнары әлеге Кагыйдәләргә территориаль зоналарның чикләрен һәм рөхсәт ителгән төзелеш объектларын төзүнең һәм реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларының шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән өлешендә үзгәрешләр кертергә хокуклы.

8. Территорияне планлаштыру документларына, эчтәлегенә, әзерләү һәм раслау тәртибенә карата гомуми таләпләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы, башка норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

## V БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар уздыру турында нигезләмәләр

### 16 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру буенча гомуми нигезләмәләр

1. Җәмәгать фикер алышулары яки гавами тыңлаулар кешенең уңайлы тормыш шартларына хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатыннан үткәрелә.

2. Җәмәгать фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, әлеге Кагыйдәләр, башка норматив хокукый актлар нигезендә үткәрелә.

3. Җирдән файдалану һәм төзелеш мәсьәләләре буенча җәмәгать фикер алышуларына яисә гавами тыңлауларга түбәндәгеләр чыгарыла:

Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектлары;

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очраклардан тыш территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне межалау проектлары;

җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләренә рөхсәтләр бирү турындагы карарлар;

рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары.

4. Җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкына җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итүне, тиешле проект белән танышуны, «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының җәмәгать фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларында катнашуын тәэмин итүче башка чараларны, кабул ителгән карарларның нигезле булуын да кертеп, җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне) күздә тотарга тиеш.

5. Җәмәгать фикер алышуларын, гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыруның тәртибе һәм башка үзенчәлекләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы нигезләмәләре белән билгеләнгән.

### 17 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектлары буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар уздыру үзенчәлекләре

1. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты яисә аларга үзгәрешләр кертү проектлары буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар Кагыйдәләр проектын әзерләү Комиссиясе тарафыннан «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы карары нигезендә уздырыла.

2. Кагыйдәләр проекты буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар дәвамлылыгы мондый проект басылып чыккан көннән алып бер айдан ким һәм өч айдан артык булмаган вакыт тәшкил итә.

3. Конкрет территориаль зона өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентына үзгәрешләр кертү өлешендә Кагыйдәләргә үзгәрешләр әзерләнгән очракта, шулай ук территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр әзерләнгән очракта, Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар мондый шәһәр төзелеше регламенты билгеләнгән территория чикләрендә, комплекслы үстерү тиешле территория чикләрендә үткәрелә. Бу очракларда җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар уздыру срогы бер айдан артык була алмый.

4. Кагыйдәләрне аэродром яны территориясендә билгеләнгән күчемсез милек объектларыннан файдалануны чикләүләргә туры китергән очракта, шулай ук 20 статьяның 2 өлешендәге г-е пунктларында күрсәтелгән ярашмауларны бетергәндә, җәмәгать фикер алышулар яки гавами тыңлаулар үткәрелми.

Конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төрләре капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең элек билгеләнгән чик параметрларын үзгәртмичә бер мәртәбә үзгәртелгән очракта, яисә капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән бер яки берничә чик параметры ун проценттан артык булмаганча бер мәртәбә үзгәртелгәндә, җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар уздыру таләп ителми.

**18 статья. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар**

1. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү тәртибе Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге бүлекнең 13 статьясы нигезләмәләре нигезендә билгеләнә.

2. Шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты иҗтимагый фикер алышуларда яки гавами тыңлауларда фикер алышырга тиеш. Җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү Комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның рөхсәт ителгән төре әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган очракта, гавами тыңлаулар мондый тискәре йогынты куркынычы янаган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре катнашында үткәрелә.

4. Комиссия түбәндәге затларга шартлы рөхсәт ителгән төргә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәрләр җибәрә:

әлеге рөхсәт соратып алына торган җир кишәрлеге белән гомуми чикләре булган җир кишәрлекләре хокук ияләренә;

әлеге рөхсәт соратып алына торган җир кишәрлеге белән гомуми чикләре булган җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә;

әлеге рөхсәт соратып алына торган капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләренә.

Күрсәтелгән хәбәрләр кызыксынган затның шартлы рәвештә рөхсәт бирү турында гаризасы алынган көннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

5. Иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр аларны уздыру турында «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкына хәбәр иткән көннән алып «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм (яисә) «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының норматив хокукый актлары белән билгеләнә һәм бер айдан артык була алмый.

6. Шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны мондый рөхсәтне алу белән кызыксынган физик яки юридик зат күтәрә.

7. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның рөхсәт ителгән төре шәһәр төзелеше регламентына җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өчен билгеләнгән тәртиптә, шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү белән кызыксынган физик яисә юридик зат инициативасы буенча җәмәгать фикер алышулары яки гавами тыңлаулар уздырганнан соң кертелгән булса, мондый затка файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар үткәрмичә кабул ителә.

**19 статья. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар**

1. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү тәртибе Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге бүлекнең 14 статьясы нигезләмәләре нигезендә билгеләнә.

2. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карар проекты җәмәгать фикер алышуларында яисә гавами тыңлауларда фикер алышырга тиеш. Җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү Комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны мондый рөхсәт алу белән кызыксынучы физик яисә юридик зат күтәрә.

**VI БҮЛЕК. Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында нигезләмәләр**

**20 статья. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе**

1. Әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 - 33 статьяларында каралган тәртиптә һәм нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

2. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү мәсьәләсен карау өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) Кагыйдәләрнең җирлекнең генераль планы һәм (яисә) муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасының күрсәтелгән генераль планга һәм (яисә) территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү нәтиҗәсендә барлыкка килгән туры килмәве;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда үтәү өчен мәҗбүри булган Кагыйдәләрдә җибәрелгән аэродром яны территориясендә урнашкан күчемсез милек объектларыннан файдалануны чикләү очракларын бетерү турында күрсәтмә керүе;

в) территориаль зоналарның чикләрен үзгәртү, шәһәр төзелеше регламентларын үзгәртү турында тәкъдимнәр керү;

г) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында чагылдырылган территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләренең урнашу урыны турындагы белешмәләрнең күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән зоналар, территорияләр чикләренең урнашу урынын тасвирлауга туры килмәве;

д) шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән территорияләреннән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә тулысынча яисә өлешчә урнашкан, Бердәм дәүләт реестрындагы күчемсез мөлкәтнең мондый зоналар, территорияләр чикләрендә күчемсез мөлкәт объектларыннан файдалануның чикләүләре федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге истәлекле урыннар җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану чикләүләренең туры килмәве;

е) территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару, мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен, федераль әһәмияттәге тарихи җирлек территориясен, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясен билгеләү, үзгәртү;

ж) территорияне комплексы үстерү турында карар кабул ителү;

з) муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан Ватанны саклаганда һәлак булганнарны күмү урыннарын ачыклау.

3. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәр Комиссиягә җибәрелә:

федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан Кагыйдәләр федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларының эшләвенә, урнашуына комачауларга мөмкин булган очракларда;

Кагыйдәләр региональ әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларының эшләвенә, урнашуына комачауларга мөмкин булган очракларда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан;

Кагыйдәләр муниципаль районның җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларының эшләвенә, урнашуына комачауларга мөмкин булган очракларда муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан;

җирлекнең тиешле территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу тәртибен камилләштерергә кирәк булган очракларда җирле үзидарә органнары тарафыннан;

муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан Ватанны саклаганда һәлак булганнарны күмү урыннары табылган очракта җирле үзидарә органнары тарафыннан;

физик яисә юридик затлар тарафыннан инициатив тәртиптә яки Кагыйдәләрне куллану нәтиҗәсендә җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары нәтиҗәле файдаланылмаса, аларның хокук ияләренә зыян салынса, җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хакы кими, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре гамәлгә ашырылмаган очракларда.

вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яисә Россия Федерациясе төзегән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат тарафыннан;

территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул иткән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы, җирле үзидарә органы, Татарстан Республикасы төзегән һәм территорияне комплекслы үстерү турында Татарстан Республикасы кабул иткән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат, яисә территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатларында территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат белән гамәлгә ашыруны тәэмин итүче зат тарафыннан.

вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан территорияне комплекслы үстерү турында кабул иткән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче Россия Федерациясе төзегән яисә устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе өлеше 50 проценттан артык тәшкил иткән юридик зат тарафыннан, яисә устав (җыелма) капиталында өлешләренең 50 проценттан артыгы шундый юридик затка караган бүленгән җәмгыять тарафыннан.

территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул иткән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы, җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе субъекты билгеләгән һәм территорияне комплекслы үстерү турында Россия Федерациясе субъекты, җирле администрация башлыгы  кабул иткән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин икән, Россия Федерациясе төзегән яисә устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе өлеше 50 проценттан артык тәшкил иткән юридик зат тарафыннан, яисә устав (җыелма) капиталында өлешләренең 50 проценттан артыгы шундый юридик затка караган бүленгән җәмгыять тарафыннан.

Кагыйдәләргә аэродром яны территориясендә билгеләнгән күчемсез милек объектларыннан файдалануның чикләүләренә туры китерүне күздә тоткан үзгәрешләр кертү проекты Комиссия тарафыннан карала алмый.

4. Кагыйдәләр белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясындагы 3.1 өлеше нигезендә җирлек территориясендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектларын территориаль планлаштыру документларында каралган (линия объектларыннан тыш) урнаштыру мөмкинлеге тәэмин ителмәгән очракта, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы, муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгына күрсәтелгән объектларны урнаштыруны тәэмин итү максатларында Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турындагы таләпне юллый.

Бу очракта «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы Кагыйдәләргә шундый таләп алынган көннән алып утыз көн эчендә үзгәрешләр кертүне тәэмин итә.

5. Расланган Кагыйдәләр җир кишәрлекләреннән һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның чикләүләренә каршы килә торган һәм чикләрендә тулысынча яисә өлешчә аэродром территориясе урнашкан аэродром яны территориясендә билгеләнгән икътисадый һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру өлешендә кулланылмый.

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органыннан күрсәтмә алгач, Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә тиеш. Күрсәтелгән күрсәтмәгә «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы суд тәртибендә шикаять бирергә мөмкин.

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы аларны аэродром яны территорияләрендә билгеләнгән күчемсез милек объектларыннан файдалануны чикләүгә туры китерү өлешендә Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертүне алты айдан артмаган срокта тәэмин итә.

6. Әлеге статьяның 2 өлешендәге г-е пунктларында каралган очракларда дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә җирле үзидарә органы территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны урнаштыруга, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләрен раслауга вәкаләтле органнар «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләреннән, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләреннән, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләреннән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрен чагылдыру өлешендә үзгәрешләр кертү турындагы таләпне җибәрә, мондый зоналар, территорияләр чикләрендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләүне билгеләү турында таләп итә.

Күрсәтелгән очракта, шулай ук территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны билгеләү, үзгәртү яисә туктату турында, мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында йә әлеге статьяның 2 өлешендәге г -е пунктларында каралган нигезләр ачыкланган көннән «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында карар кабул итәргә тиеш. Шул ук вакытта әлеге өлештә каралган таләп нигезендә аларны төгәлләштерү максатларында җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләрне раслау таләп ителми.

Территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрен чагылдыру, мәдәни мирас объектлары теририторияләрен, федераль әһәмиятле тарихи җирлекләр территорияләрен, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләрен, мондый зоналар, территорияләр чикләрендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның чикләүләрен билгеләү өлешендә Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару агыйдәләренә үзгәрешләр кертү срогы территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен билгеләү, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләрен раслауга вәкаләтле дәүләт хакимиятенең башкарма органыннан яки җирле үзидарә органыннан таләп кергән көннән, мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында хокукларны теркәү органыннан территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаның гамәлдә булуын билгеләү, үзгәртү яисә туктату турында белешмәләр кергән, яки әлеге статьяның 2 өлешендәге г - е пунктларында каралган җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өчен нигезләр ачыкланган көннән алып алты айдан да арта алмый.

7. Территорияне комплекслы үстерү турында карар гамәлгә ашыру максатларында Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертелгән очракта, мондый үзгәрешләр территорияне комплекслы үстерү максатларында территорияне планлаштыру проектын раслаган көннән алып туксан көннән дә соңга калмыйча кертелергә тиеш.

8. Әлеге статьяның 4 һәм 5 өлешләрендә каралган, шулай ук әлеге статьяның 2 өлешендәге г-е пунктларында күрсәтелгән чагышмауларны бетергән очракларда, җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар уздыру таләп ителми.

9. Комиссия, Кагыйдәләргә аэродром яны территорияләрендә билгеләнгән күчемсез милек объектларыннан файдалануны чикләүгә туры китерү өлешендә, һәм әлеге статьяның 2 өлешендәге г-е пунктларында күрсәтелгән чагышмауларны бетергән очракларда үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш, Кагыйдәгә үзгәреш кертү турында тәкъдим кертелгән көннән алып уегерме биш көн эчендә бәяләмә әзерли, ул Кагыйдәләргә кергән тәкъдимнәр нигезендә үзгәрешләр кертү турында рекомендацияләрне үз эченә ала, яисә мондый тәкъдимне кире кагу турында, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп һәм бу бәяләмәне «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрә.

10. «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе, Комиссия бәяләмәсендәге рекомендацияләрне исәпкә алып, утыз көн эчендә Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында яисә, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимне кире кагу хакында карар кабул итә һәм мондый карарның күчермәсен мөрәҗәгать итүчеләргә җибәрә.

11. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү җирле үзидарәнең вәкиллекле органы тарафыннан расланса, җирле үзидарәнең вәкиллекле органына җибәрелгән Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турындагы проект күрсәтелгән орган утырышында якындагы утырыштан соң килүче утырыштан соңга калмыйча каралырга тиеш.

12. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турындагы карар (карар) күрсәтелгән проектны әзерләү эшләрен уздыру тәртибен һәм срокларын, проектны әзерләүгә кагылышлы башка нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш.

13. «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында карар кабул итү көненнән алып ун көн эчендә мондый карар кабул итү турындагы хәбәрне билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны (халыкка җиткерүне) тәэмин итә. Хәбәрдә күрсәтелә:

Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен уздыру тәртибе һәм сроклары;

кызыксынган затларның Комиссиягә тәкъдимнәр җибәрү тәртибе;

эшләрне оештыруның башка мәсьәләләре.

Кагыйдәләр аэродром яны территориясендә билгеләнгән күчемсез милек объектларыннан файдалануны чикләүгә туры китергән очракта, шулай ук әлеге статьяның 2 өлешендәге г-е пунктларында күрсәтелгән чагышмауларны бетергән очракларда, Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында карар кабул итү турындагы хәбәрне бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.

14. Федераль әһәмияттәге тарихи җирлек территориясенә яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясенә карата әзерләнгән Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проекты мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы, мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән гамәлдәге законнар нигезендә килештерелергә тиеш.

Федераль яисә региональ әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территориясе чикләрендә тулысынча торак пунк турнашкан очракта, әлеге махсус сакланылучы табигать территориясе чикләрендә урнашкан шундый торак пункт территориясенә карата әзерләнгән җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты махсус саклана торган табигать территориясен үз карамагында тоткан федераль башкарма хакимият органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән килештерелергә тиеш. Килештерү предметы булып, күрсәтелгән торак пункт территориясенә карата билгеләнә торган шәһәр төзелеше регламентының махсус сакланылучы табигать территорияләре турында Россия Федерациясе законнарында һәм махсус саклана торган табигать территориясе турындагы нигезләмәдә каралган махсус саклау режимына туры килүе тора. Килештерү Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

15. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләгәннән соң, «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Комиссия тәкъдим иткән проектны техник регламентлар, территориаль планлаштыру документлары таләпләренә, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларында булган белешмәләргә, документларга һәм материалларга туры килүен тикшерә.

16. Күрсәтелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгына Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын җибәрә яисә аның әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә һәм документларга туры килмәве ачыкланган очракта, Комиссиягә эшләп бетерү өчен җибәрә.

17. «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын алганда проектны алган көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча проект буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздыру турында карар кабул итә.

18. Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар әлеге Кагыйдәләрнең 17 статьясы нигезләмәләре нигезендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

19. Кагыйдәгә үзгәрешләр җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга һәм «Интернет» челтәрендә «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең яисә муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

20. Кагыйдәләргә үзгәрешләр территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын раслау датасыннан ун көннән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.

21. Физик һәм юридик затлар Кагыйдәләргә суд тәртибендә үзгәрешләрне раслау турындагы карарга ризасызлык белдерергә хокуклы.

## VII БҮЛЕК. Җирдән файдалануның һәм төзелешнең башка мәсьәләләрен җайга салу турында нигезләмәләр

### 21 статья. Территориаль зоналар чикләре турында мәгълүматны күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрына кертү

1. Территориаль зоналар чикләре турында күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрына белешмәләр кертү кагыйдәләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 32, 34 статьялары нигезләмәләре белән билгеләнә.

2. Әлеге Кагыйдәләр белән территориаль зоналар, шул исәптән чикләре күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында булган җир кишәрлекләре, торак пунктлар яисә муниципаль берәмлекләрнең чикләре урынын билгеләүдә хаталарны исәпкә алып билгеләнә.

Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында белешмәләре булмаган торак пунктлар чикләренә карата аларның чикләрен билгеләүдәге хаталар исәпкә алынмый.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

# ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

**II КИСӘК.** ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕН ЗОНАЛАШТЫРУ КАРТАЛАРЫ

**III КИСӘК.** ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ РЕГЛАМЕНТЛАРЫ

2023 ел

# ЭЧТӘЛЕК

ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕНЕҢ СОСТАВЫ ……………....27
II КИСӘК. ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕН ЗОНАЛАШТЫРУ КАРТАЛАРЫ ……………………...27
VIII БҮЛЕК. «Коркачыкавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары …………………………………………………………..........................28
22 статья. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары. Территориаль зоналар ………………**Ошибка! Закладка не определена.**
23 статья. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары. Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре ……………………………………………………………...…**Ошибка! Закладка не определена.**
24 статжя. Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары. Мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре, тарихи җирлекләр территорияләре чикләре, мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләре ………………………………………………………………………......................**Ошибка! Закладка не определена.**
III КИСӘК. ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ РЕГЛАМЕНТЛАРЫ ………………………………...30
IX БҮЛЕК. Шәһәр төзелеше регламентлары җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен, җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен һәм рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларын билгеләү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү өлешендә ……………………………………………………..…...........30
25 статья. Территориаль зоналар ………………………………………………………………..**Ошибка! Закладка не определена.**
26 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары гамәлдә булуы кагылмый торган территорияләр ......**Ошибка! Закладка не определена.**
27 статья. Шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган территорияләр ……….................**Ошибка! Закладка не определена.**
X БҮЛЕК. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләүләр …………………………………………………………………………………….............**Ошибка! Закладка не определена.**
28 статья. Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар ……………………...**Ошибка! Закладка не определена.**
29 статья. Мәдәни мирас объектларын саклау шартлары буенча җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануны чикләүләр ……………………………..............44
XI БҮЛЕК. Территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп күрсәткечләре һәм мондый объектларның халык өчен территориаль мөмкин булган максималь күләменең исәп-хисап күрсәткечләре ..........................................................................................................................**Ошибка! Закладка не определена.**
30 статья. Төп нигезләмәләр ………………………………………………………………..49
XII БҮЛЕК. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләрен тасвирлау ……...**Ошибка! Закладка не определена.**
31 статья. Төп нигезләмәләр ……………………………………………………………….**Ошибка! Закладка не определена.**

- **ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ СОСТАВЫ**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (алга таба - Кагыйдәләр) түбәндәге составта эшләнде:

**I кисәк.** Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану тәртибе, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе

**II кисәк.** Шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары

График материаллар:

| № т/б | Исеме | Масштаб |
|---|---|---|
| 1 | Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы.<br>Территориаль зоналар | 1:10 000 |
| 2 | Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы.<br>Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре | 1:10 000 |

**III кисәк.** Шәһәр төзелеше регламентлары

**Кушымта**
Территориаль зоналар чикләре турында белешмәләр

## • II КИСӘК. ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕН ЗОНАЛАШТЫРУ КАРТАЛАРЫ

### VIII БҮЛЕК. «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары

#### 22 статья. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар

1. Шәһәр төзелешен зоналаштыруның күрсәтелгән картасы әлеге Кагыйдәләрнең аерылгысыз өлеше булып тора.

2. Күрсәтелгән картада түбәндәгеләр чагылдырылган:

территориаль зоналарның чикләре һәм аларның код билгеләре;

шәһәр төзелеше регламентларының гамәле кагылмый торган территорияләр;

шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган территорияләр.

Территориаль зоналарның чикләре әлеге Кагыйдәләрнең 1 томының 9 статьясы нигезләмәләре нигезендә билгеләнде.

3. «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә территориаль зоналарның түбәндәге төрләре күрсәтелгән:

индивидуаль торак төзелеше зоналары;

аз катлы торак төзелеше зоналары;

күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле төзелеш зоналары;

транспорт инфраструктурасы зоналары

инженерлык инфраструктурасы зоналары;

җитештерү зоналары;

склад зоналары;

гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчә бакчачылыгы берләшмәләре зоналары (яшелчә бакчачылыгы);

зиратлар зоналары.

4. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында, мондый эшчәнлекне гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта, чикләрендә территорияне комплекслы үстерү күздә тотыла торган территорияләр мәҗбүри тәртиптә билгеләнә. Мондый территорияләрнең чикләре бер яки берничә территориаль зона чикләрендә билгеләнә.

Территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр чикләре җирле үзидарәнең вәкаләтле органы территорияне комплекслы үстерү турындагы карары һәм территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документлары нигезендә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы һәм ачык аукционда җиңүче арасында территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү хокукына ия булган яисә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә мондый шартнамә төзү хокукына ия башка затлар арасында төзелгән территорияне планлаштыру документлары нигезендә билгеләнә.

Чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру каралган территорияләр «Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрендә билгеләнмәгән, шуңа бәйле рәвештә әлеге Кагыйдәләр материалларында чагылдырылмаган.

#### 23 статья. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре

1. Шәһәр төзелешен зоналаштыруның күрсәтелгән картасы әлеге Кагыйдәләрнең аерылгысыз өлеше булып тора (2 нче кушымта).

2. Күрсәтелгән картада чагылдырылган:

Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә яисә расланган зона проектына нигезләнеп чагылдырылган, билгеләнгән тәртиптә расланган территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре;

норматив-техник документлар таләпләре һәм кагыйдәләр (якынча) нигезендә сайлап алынган территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре.

3. Билгеләнгән тәртиптә расланган, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләре нигезендә йә расланган зона проектына нигезләнеп чагылдырылган территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануга өстәмә чикләүләр сала. Характеристикалары законнарда, башка норматив хокукый актларда билгеләнгән куллану режимнарына туры килми торган территориядән файдалануның махсус шартлары булган мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары әлеге Кагыйдәләргә туры килми торган булып санала.

**24 статья. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре, тарихи җирлекләр территорияләре чикләре, мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләре**

1. Шәһәр төзелешен зоналаштыруның күрсәтелгән картасында мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләре күрсәтелә.

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә мәдәни мирас объектларын саклау зоналарының билгеләнгән чикләре булмаганга күрә, әлеге Карта әзерләнми.

- **III КИСӘК. ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ РЕГЛАМЕНТЛАРЫ**

**IX БҮЛЕК. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләрен, җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларын билгеләү өлешендә Шәһәр төзелеше регламентлары**

**25 статья. Территориаль зоналар**

**1. Индивидуаль торак йортлар төзелеше зоналары**

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә түбәндәге индивидуаль торак йортлар төзелеше зоналары күрсәтелде:

| Зонаның исеме | Зонаның индексы |
|---|---|
| индивидуаль торак төзелеше зонасы Ж1 | Ж1 |

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре; җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары:

| Рөхсәт ителгән файдалану төренең коды * | Рөхсәт ителгән файдалану төренең исеме * | Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | җир кишәрлегенең күләме (кв.м) | катларның чик саны һәм төзелешнең чик биеклеге | төзелешнең максималь проценты (%) | җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенүләр |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре** | | | | | |
| 2.1 | Индивидуаль торак төзелеше өчен | минималь – 1000; максималь – 2500. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1; Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 10 м; ярдәмче корылмалар - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (кыек түбәле, конёкта биеклеге). Коймаларның максималь биеклеге - 2,0 м. | 20 | 5 м - урамга чыгучы җир кишәрлеге якларыннан; 3 м – төп төзелеш өчен башка якларыннан; ян юлга чыга торган яктан ярдәмче корылмалар өчен; 1 м - урам-юл челтәренә чыкмый торган яклардан ярдәмче корылмалар өчен |
| 2.2 | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт яны җир кишәрлеге) | минималь – 1000; максималь – 2500. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1; Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 10 м; ярдәмче корылмалар - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (скат түбәле, конёкта биеклеге). Коймаларның максималь биеклеге - 2,0 м. | 20 | 5 м - урамга чыгучы җир кишәрлеге якларыннан; 3 м – төп төзелеш өчен башка якларыннан; ян юлга чыга торган яктан ярдәмче корылмалар өчен; 1 м - урам-юл челтәренә чыкмый торган яклардан ярдәмче корылмалар өчен |
| 2.3 | Блокланган торак төзелеше | минималь – 1000; максималь – 2500 | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1; | 30 | 5 м - урамга чыгучы җир кишәрлеге якларыннан; 3 м – төп төзелеш өчен башка якларыннан; ян юлга |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 10 м; ярдәмче корылмалар - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (скат түбәле, конёкта биеклеге). Коймаларның максималь биеклеге - 2,0 м. | | чыга торган яктан ярдәмче корылмалар өчен; 1 м - урам-юл челтәренә чыкмый торган яклардан ярдәмче корылмалар өчен |
| 2.7 | Торак төзелешенә хезмәт күрсәтү | билгеләнми | билгеләнмиләр | 100 | билгеләнмиләр |
| 2.7.1 | Автотранспорт саклау | билгеләнми | билгеләнмиләр | 100 | билгеләнмиләр |
| 2.7.2. | Гаражларны үз ихтыяҗлары өчен урнаштыру | билгеләнми | билгеләнмиләр | 100 | билгеләнмиләр |
| 12.0 | Гомуми файдалану җир кишәрлекләре (территорияләр) | билгеләнми | билгеләнмиләр | билгеләнми | билгеләнмиләр |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре** | | | | | |
| билгеләнмиләр | | | | | |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләре** | | | | | |
| 2.1.1 | Аз катлы күпфатирлы торак төзелеше | минималь – 400; максималь – билгеләнми. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 4 (мансардны да кертеп); Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 15 м; Койманың максималь биеклеге - 1 м. | 40 | 5 м. |
| 4.9.1.3 | Автомобиль юу урыннары | билгеләнми | билгеләнмиләр | билгеләнми | билгеләнмиләр |
| 4.9.1.4 | Автомобильләрне ремонтлау | билгеләнми | билгеләнмиләр | билгеләнми | билгеләнмиләр |
| 13.1 | Яшелчәчелек алып бару | минималь – 1000; максималь – 2500. | билгеләнмиләр | билгеләнми | билгеләнмиләр |

* Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең 10.11.2020 ел № П/0412 боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы нигезендә

Башка таләпләр:

Автомобиль транспортын саклау урыннарыннан тыш, барлык ярдәмче корылмаларны урамнар ягыннан урнаштыру рөхсәт ителми.

Әлеге статьяда җайга салынмаган күрсәткечләр техник регламентлар, норматив техник документлар, шәһәр төзелешен проектлау нормативлары һәм башка норматив документлар таләпләре нигезендә билгеләнә.

## 2. Аз катлы торак йортлар төзелеше зоналары

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә аз катлы торак йортлар төзелешенең түбәндәге зоналары күрсәтелде:

| Зонаның исеме | Зонаның индексы |
|---|---|
| аз катлы торак йортлар төзелеше зонасы Ж2 | Ж2 |

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре; җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары:

| **Рөхсәт ителгән файдаланy төренең коды *** | **Рөхсәт ителгән файдалану төренең исеме *** | **Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары** | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **җир кишәрлеге күләме (кв.м)** | **катларның чик саны һәм төзелешнең чик биеклеге** | **төзелешнең максималь проценты (%)** | **җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенүләр** |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре** | | | | | |
| 2.1.1 | Аз катлы күпфатирлы торак төзелеше | минималь – 1000; максималь – билгеләнми. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 4 (мансардны да кертеп); Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 15 м; Койманың максималь биеклеге - 1 м. | 40 | 5 м. |
| 2.3 | Блокланган торак төзелеше | минималь – 1000; максималь – 2500. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1; Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 10 м; ярдәмче корылмалар - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (скат түбәле, конёкта биеклеге). Коймаларның максималь биеклеге - 2,0 м. | 30 | 5 м - урамга чыгучы җир кишәрлеге якларыннан; 3 м – төп төзелеш өчен башка якларыннан; ян юлга чыга торган яктан ярдәмче корылмалар өчен; 1 м - урам-юл челтәренә чыкмый торган яклардан ярдәмче корылмалар өчен |
| 2.7 | Торак төзелешенә хезмәт күрсәтү | билгеләнми | билгеләнмиләр | 100 | билгеләнмиләр |
| 2.7.1 | Автотранспортны саклау | билгеләнми | билгеләнмиләр | 100 | билгеләнмиләр |
| 2.7.2 | Гаражларны үз ихтыяҗлары өчен урнаштыру | билгеләнми | билгеләнмиләр | 100 | билгеләнмиләр |
| 12.0 | Гомуми файдалану җир кишәрлекләре (территорияләр) | билгеләнми | билгеләнмиләр | билгеләнми | билгеләнмиләр |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре** | | | | | |
| билгеләнмиләр | | | | | |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләре** | | | | | |
| 2.1 | Индивидуаль торак төзелеше өчен | минималь – 1000; максималь – 2500. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1; Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 10 м; ярдәмче корылмалар - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (скат түбәле, конёкта биеклеге). Коймаларның | 20 | 5 м - урамга чыгучы җир кишәрлеге якларыннан; 3 м – төп төзелеш өчен башка якларыннан; ян юлга чыга торган яктан ярдәмче корылмалар өчен; 1 м - урам-юл челтәренә чыкмый торган яклардан |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | максималь биеклеге - 2,0 м. | | ярдәмче корылмалар өчен |
| 2.2 | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт яны җир кишәрлеге) | минималь – 1000; максималь – 5000. | Төп төзелештәге катларның иң чик саны - 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмалар - 1; Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 10 м; ярдәмче корылмалар - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (скат түбәле, конёкта биеклеге). Коймаларның максималь биеклеге - 2,0 м. | 20 | 5 м - урамга чыгучы җир кишәрлеге якларыннан; 3 м – төп төзелеш өчен башка якларыннан; ян юлга чыга торган яктан ярдәмче корылмалар өчен; 1 м - урам-юл челтәренә чыкмый торган яклардан ярдәмче корылмалар өчен |
| 4.9.1.3 | Автомобиль юу урыннары | билгеләнми | билгеләнмиләр | билгеләнми | билгеләнмиләр |
| 4.9.1.4 | Автомобильләрне ремонтлау | билгеләнми | билгеләнмиләр | билгеләнми | билгеләнмиләр |
| 13.1 | Яшелчәчелек алып бару | минималь – 1000; максималь – 2500. | билгеләнмиләр | билгеләнми | билгеләнмиләр |

* Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең 10.11.2020 ел № П/0412 боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы нигезендә

Башка таләпләр:

Автомобиль транспортын саклау урыннарыннан тыш, барлык ярдәмче корылмаларны урамнар ягыннан урнаштыру рөхсәт ителми.

Социаль, коммуналь-көнкүреш, административ һәм башка билгеләнештәге рөхсәт ителгән объектлар торак йортларның аскы ике катында урнаша ала яки, әгәр аларның килүчеләргә торак (ишегалды) территориясеннән аерым керү урыны, автотранспортны вакытлыча куярга ачык кунак автостоянкаларын оештыру өчен килү юллары һәм мәйданчыклары булган очракта, янкорма итеп төзелә ала.

Әлеге статьяда җайга салынмаган күрсәткечләр техник регламентлар, норматив техник документлар, шәһәр төзелешен проектлау нормативлары һәм башка норматив документлар таләпләре нигезендә билгеләнә.

## 3. Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зоналар

«Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә түбәндәге күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле төзелеш зоналары тәкъдим ителде:

| Зонаның исеме | Зонаның индексы |
|---|---|
